МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ
И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН
ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ
ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.11.2017 № 832-пр

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2018 елның 11 гынварендә теркәлде, № 4513

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Техноген һәлакәтләр аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 16 июлендәге 565 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Техноген һәлакәтләр аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында, боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Техноген һәлакәтләр аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 16 июлендәге 565 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 05 октябрендәге 703 номерлы, 2016 елның 07 июнендәге 317 номерлы, 2017 елның 08 июнендәге 350 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе директоры Р.Р. Фәйзуллинга Регламент нигезләмәләренең тайпылышсыз үтәлүен тәэмин итәргә.»;

Күрсәтелгән боерык белән расланган Техноген һәлакәтләр аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 16.07.2012 № 565 боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 27.11.2017 № 832 боерыгы редакциясендә)

**Техноген һәлакәтләр аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

# 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Техноген һәлакәтләр аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) техноген һәлакәтләр аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алучылар:

1) Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә яисә Чернобыль АЭСында һәлакәт нәтиҗәләрен бетерүгә бәйле рәвештә нурланыш авыруы яисә башка авырулар алган яисә кичергән гражданнар;

2) Чернобыль һәлакәте аркасында инвалидка әйләнгән затлар, түбәндәгеләр исәбеннән:

зарарланган зона чикләрендә һәлакәт нәтиҗәләрен бетерүдә катнашкан яисә эксплуатацияләү эшләренә җәлеп ителгән яки Чернобыль АЭСында башка эшләрдә катнашкан гражданнар (шул исәптән вакытлыча җибәрелгән яисә командировкаланган);

махсус җыеннарга чакыртылган, зарарланган зона чикләрендә Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүгә бәйле эшләр башкаруга җәлеп ителгән хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби бурычлы кешеләр, урнашу урынына һәм башкарылган эшләренә бәйсез рәвештә, шулай ук зарарланган зонада хезмәт иткән (итүче) эчке эшләр органнары, Янгынга каршы дәүләт хезмәте җитәкчеләре һәм гади хәрби хезмәткәрләр составындагы затлар;

зарарланган зоналардан эвакуацияләнгән һәм читләштерү зонасыннан күчерелгән яисә күрсәтелгән зоналардан эвакуацияләү турында карар кабул ителгәннән соң ирекле тәртиптә чыгып киткән гражданнар;

Чернобыль һәлакәте аркасында зыян күргән һәм кешеләрнең гомерен саклау өчен җелек мие биргән гражданнар, җелек миен трансплантацияләү вакытыннан соң узган вакытка һәм аларда шуңа бәйле рәвештә инвалидлык үсеш алган вакытка бәйсез рәвештә;

3) 14 яшенә җитмәгән, Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган, әлеге пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән гражданнар белән яшәүче балалар;

4) 1986-1987 елларда читләштерелгән зонада Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләрен бетерү эшләрендә яисә шушы чорда халыкны, матди кыйммәтләрне, авыл хуҗалыгы терлекләрен эвакуацияләүгә бәйле эшләрдә һәм Чернобыль АЭСында эвакуацияләүдә яисә башка эшләрдә мәшгуль булган (шул исәптән вакытлыча җибәрелгән яисә командировкаланган) гражданнар; махсус җыеннарга чакыртылган һәм шушы чорда читләштерү зонасы чикләрендә Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүгә бәйле эшләр башкару өчен җәлеп ителгән хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби бурычлы затлар, гражданлык авиациясенең очу-күтәртү, инженер-техник составын да кертеп, дислокация һәм башкарылган эшләр урынына бәйсез рәвештә; 1986-1987 елларда читләштерү зонасында хезмәт иткән эчке эшләр органнарының җитәкчелек һәм рядовой состав затлары; 1988-1990 елларда хәрби җыеннарга чакыртылган һәм «Укрытие» объекты буенча эшләрдә катнашкан гражданнар, шул исәптән хәрби хезмәткәрләр һәм хәрби бурычлы затлар; 1986 елның 26 апреленнән 30 июненә кадәрге чорда Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә зыян күргән һәм ионлаштыручы нурланыш чыганагы булып торган затларга медицина ярдәме күрсәткәндә һәм хезмәт күрсәткәндә нурланышның нормадан артык дозасын алган кече һәм урта медицина персоналы, табиблар һәм дәвалау учреждениеләренең башка хезмәткәрләре (һөнәри эшчәнлеге уздырыла торган эш профиленә туры килә торган эш урыннарында радиация торышы шартларында теләсә нинди ионлаштыручы нурланыш чыганаклары белән эшләүгә бәйле булган затлардан тыш);

5) 1986 елда зарарланган зонадан эвакуацияләнгән (шул исәптән ирекле рәвештә чыгып киткән) яисә күчерелгән гражданнар, балаларны, шул исәптән эвакуацияләгән вакытта ана карынында булган балаларны да кертеп;

6) махсус җыеннарга чакыртылган хәрби хезмәткәрләрне һәм хәрби бурычлы затларны, эчке эшләр органнарының, дәүләт иминлеге органнарының, гражданлык оборонасы органнарының җитәкчелек итүче һәм рядовой состав затларын да кертеп, 1957-1958 елларда 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә авария нәтиҗәләрен бетерү эшләрендә турыдан-туры катнашкан (шул исәптән вакытлыча җибәрелгән яисә командировкаланган) гражданнар, шулай ук, Махсус җыеннарга чакыртылган хәрби хезмәткәрләрне һәм хәрби бурычлы затларны, эчке эшләр органнарының, дәүләт иминлеге органнарының, гражданлык оборонасы органнарының җитәкчелек итүче һәм рядовой состав затларын да кертеп, 1949-1956 елларда Тичә елгасы буйлап радиоактив пычранган

территорияләрендә яклау чараларын уздыру һәм тернәкләндерү эшләрендә мәшгуль булган гражданнар;

7) 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә авария һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар әләгү аркасында радиоактив пычрануга дучар булган торак пунктларыннан эвакуацияләнгән (күчерелгән), шулай ук ирекле рәвештә чыгып киткән (шул исәптән эвакуацияләү (күчерү) өлешчә башкарылган торак пунктлары чикләрендә эвакуацияләнгән (күчерелгән)) гражданнар, балаларны, шул исәптән эвакуацияләү (күчерү) вакытына ана карынында булган балаларны да кертеп, шулай ук 1957 елда радиоактив пычрану зонасыннан эвакуацияләнгән хәрби хезмәткәрләр, хәрби частьләрнең ирекле ялланган составы һәм махсус контингент. Ирекле рәвештә чыгып киткән гражданнарга 1957 елның 29 сентябреннән башлап 1960 елның 31 декабренә кадәрге чорда 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә авария аркасында радиоактив пычрануга дучар булган торак пунктларыннан чыгып киткән, шулай ук 1949 елдан башлап 1962 ел тәмамланганчыга кадәр Тичә елгасына радиоактив калдыклар әләгү аркасында радиоактив пычрануга дучар булган торак пунктларыннан чыгып киткән (шул исәптән күчерү эшләре өлешчә алып барылган торак пунктлары чикләрендә күченгән) гражданнар керә;

8) нурланыш авыруы, килеп чыгышы яисә катлаулануы 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар әләгү аркасында радиация тәэсире белән аңлатылган авырулар исемлегенә кертелгән башка авырулар алган, «1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар әләгү аркасында радиация тәэсиренә дучар булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында» 1998 елның 26 ноябрендәге 175-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 175-ФЗ номерлы Федераль закон) 1 статьясында күрсәтелгән гражданнар исәбендәге гражданнар;

9) 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар әләгү аркасында инвалидка әйләнгән, 175-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясында күрсәтелгән гражданнар исәбендәге затлар;

10) 14 яшенә җитмәгән, шушы пунктның 8 һәм 9 пунктчаларында күрсәтелгән гражданнар белән яшәүче балалар;

11) Россия Федерациясе Югары Советының «Чернобыль АЭСында һәлакәт аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» РСФСР Законы гамәленең аеруча куркыныч бүлекчәләрдәге гражданнарга кагылуы турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2123-1 номерлы карарының (алга таба – 2123-1 номерлы РФ ЮС карары) 1 статьясында күрсәтелгән, аеруча куркыныч бүлекчәләрдәге гражданнар;

12) 2123-1 номерлы карарның 1 статьясында күрсәтелгән аеруча куркыныч бүлекчәләрдәге инвалидка әйләнгән гражданнар;

13) 14 яшенә җитмәгән балалар, түбәндәгеләр белән яшәүче:

2123-1 номерлы РФ ЮС карарының 1 статьясының «а»-»г» пунктчаларында күрсәтелгән аеруча куркыныч бүлекчәләрдән булган гражданнар;

2123-1 номерлы РФ ЮС карарының 1 статьясында күрсәтелгән аеруча куркыныч бүлекчәләрдән булган, инвалидка әйләнгән гражданнар;

14) Чернобыль АЭСында һәлакәт нәтиҗәсендә вафат булган, Чернобыль һәлакәтенә бәйле рәвештә барлыкка килгән нурланыш авыруы һәм башка авырулар нәтиҗәсендә вафат булган гражданнар исәбендәге тукландыручысын югалткан гаиләләр, шулай ук «Чернобыль АЭСында һәлакәт нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законының (алга таба – 1244-1 номерлы РФ Законы) 14 статьясында күрсәтелгән, социаль ярдәм чаралары кагылган, вафат булган инвалидларның гаиләләре;

15) «Маяк» җитештерү берләшмәсендә һәлакәт аркасында инвалидка әйләнгән һәм нурланыш авыруы, барлыкка килүе яисә катлаулануы 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар әләгү аркасында радиация тәэсире белән аңлатыла торган авырулар исемлегенә кертелгән башка авыруларны алган гражданнар исәбендәге тукландыручысын югалткан гаиләләрдән, үлем очрагы 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар әләгү нәтиҗәсендә радиация тәэсире аркасында барлыкка килгән очракта;

16) аеруча куркыныч бүлекчәләрдән булган гражданнар исәбеннән тукландыручысын югалткан гаиләләр;

17) Чернобыль һәлакәте аркасындагы яисә ата-анасының берсенең радиоактив нурланыш алуының генетик нәтиҗәләре белән аңлатылган авырулардан интегүче балалар һәм яшүсмерләр;

18) 175-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясында күрсәтелгән гражданнар исәбендәге ата-аналары алган радиация тәэсире аркасында авырулардан интегүче беренче һәм аннан соңгы буын балалар;

19) 1949-1963 елларда Россия Федерациясе территориясендә һәм аннан читтә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан Семипалат полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация тәэсиренә дучар булган торак пунктлары исемлегенә кертелгән торак пунктларында яшәгән һәм нурланышның суммар (тупланган) рәвештә 25 сЗв (бэр) артып китә торган нәтиҗәле дозасын алган гражданнар.

Гражданнарның әлеге пунктта күрсәтелгән категорияләре исәбендәге, хәзерге вакытта хәрби хезмәткәрләр, эчке эшләр органнары, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары, Янгынга каршы дәүләт хезмәтенең янгынга каршы федераль хезмәте, наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен тикшереп тору органнары, Россия Федерациясе таможня органнары хезмәткәрләре, алар исәбендәге пенсионерлар, шул исәптән хәзер эшләми торган (эш урынына бәйсез рәвештә), күрсәтелгән федераль башкарма хакимият органнарының гражданлык персоналы, шулай ук федераль салым полициясе органнарыннан куылган затлар исәбендәге пенсионерлар, шул исәптән эшләми торган (эш урынына бәйсез рәвештә), радиация тәэсиренә дучар булган затлар дәүләт хезмәте алучыларга керми.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча мөрәҗәгать итүчеләр булып Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәтен алучылар яисә аларның законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яки дәүләт хезмәте алучылардан билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә эш

йөртүгә вәкаләт алган затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче) тора.

1.4. Дәүләт хезмәте «Республикасы матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Үзәк) тарафыннан дәүләт хезмәте алучының даими яшәгән урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Үзәк бүлегендә (алга таба – Үзәк бүлеге) күрсәтелә.

1.4.1. Үзәк бүлегенең урнашу урыны, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турында мәгълүмат әлеге Регламентка белешмәлек кушымтада күрсәтелде.

Үзәк бүлегенең эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, Үзәк бүлегенең Үзәкнең эчке тәртип кагыйдәләрендә билгеләнә торган эш сәгатьләрендә.

Гаризалар кабул итү графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, Үзәкнең эчке тәртип кагыйдәләрендә билгеләнә торган эш сәгатьләрендә.

1.4.2. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматлардан торучы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында (алга таба – Министрлык), Үзәк бүлекләрендә урнашкан дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат шушы Регламентның 1.1, 1.4.1, 1.5, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте турында белешмәләрне үз эченә ала.

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә – (алга таба – «Интернет» челтәре):

Министрлыкның http://mtsz@tatarstan.ru рәсми сайтында;

Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Үзәк бүлегенә, Үзәккә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Үзәк бүлегенә, Үзәккә, Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә)(http://mtsz@tatar.ru).

1.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Үзәк бүлеге биналарындагы мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.5. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

«Чернобыль АЭСында һәлакәт аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законы («Ведомости Съезда народных депутатов и Верховного Совета РСФСР», 1991, № 21, 699 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Гражданлык хәле актлары турында» 1997 елның 15 ноябрендәге 143-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 143-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 1997, № 47, 5340 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар эләгү аркасында радиация тәэсиренә дучар булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында» 1998 елның 26 ноябрендәге 175-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 1998, № 48, 5850 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Семипалат полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга социаль гарантияләр турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 2-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 2-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 2002, № 2, 128 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 152-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2006, № 31 (1өл.), 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон), (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт белән идарә итү системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указы (алга таба – РФ Президентының 601 номерлы указы) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Гражданлык кодексы (беренче кисәк) (РФ Законнар җыентыгы, 1994, № 32, 3301 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Югары Советының «Чернобыль АЭСында һәлакәт аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» РСФСР Законы гамәленең аеруча куркыныч бүлекчәләрдәге гражданнарга кагылуы турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2123-1 номерлы карары (Ведомости Съезда народных депутатов РСФСР и Верховного Совета РСФСР, 1992, № 4, 138 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Чернобыль АЭСында һәлакәт аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга социаль булышлык күрсәтү турында» 2004 елның 31 декабрендәге 907 номерлы карары белән расланган Чернобыль АЭСында һәлакәт аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен түләнә торган акчалата компенсация бирү кагыйдәләре (алга таба – 1 кагыйдәләр) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2005, № 2, 164 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 30 декабрендәге 882 номерлы карары белән расланган Семипалат полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-

төлек товарлары сатып алуга ай саен түләнә торган акчалата компенсация бирү кагыйдәләре (алга таба – 2 кагыйдәләр) (РФ Законнар җыентыгы, 2005, № 2, 151 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Чернобыль АЭСында һәлакәт аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» Россия Федерациясе законында, «1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә авария һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар эләгү аркасында радиация тәэсиренә дучар булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында» Федераль законда һәм «Семипалат полигонында атом-төш сынау-лары аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга социаль гарантияләр турында» Федераль законда күздә тотылган зыянны каплау һәм гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрү буенча Россия Федерациясе чыгым йөкләмәләрен финанс ягыннан тәэмин итүнең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 30 августындагы 542 номерлы карары белән расланган кагыйдәләре (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2005, № 36, 3707 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә һәм айлык акчалата түләүләр түләүгә субсидияләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек турында» 2005 елның 22 гыйнварындагы 20 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы», 2005, № 5, 0156 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзеге булдыру турында» 2005 елның 20 июнендәге 296 номерлы карары (алга таба – 296 номерлы ТР МК карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2005, № 25, 0593 ст.);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – 880 номерлы ТР МК карары белән расланган Тәртип) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма

хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

1.6. Бу регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – дәүләт хезмәтен күрсәтүче учреждение тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата).

дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документларны кабул итү һәм тапшыру, мөрәҗәгать итүчеләрне консультацияләү тәрәзәсе.

Бу Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясының 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә аңлашыла. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше шушы Регламентның 1 нче кушымтасында китерелде.

## 2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләп билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Техноген һәлакәтләр аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен түләнә торган акчалата компенсация (алга таба – компенсация) билгеләү | 1244-1 номерлы РФ Законының 14 ст. 1 өл. 13 п., 15 ст. 1 өл. 3 п.;<br>1 кагыйдәләрнең 1 п.;<br>2 кагыйдәләрнең 1 п.; |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы (учреждениесе) исеме | Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлеге | 1 кагыйдәләрнең 2 п.;<br>2 кагыйдәләрнең 3 п.; |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар | |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, | Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар шушы Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар (ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша гарызнамә җибәрү зарурлыгы булмаган очракта) килгән көннән башлап биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. | |

| | |
|---|---|
| Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча документлар сорату зарурлыгы булганда дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты гаризаны һәм документларны теркәгән көннән соң ун эш көненә кадәр озайтыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү чорын туктатып тору каралмаган |
| 2.5. Закон яисә бүтән норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле һәм зарури хезмәтләр күрсәтү өчен зарури, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 1. Компенсация билгеләү турында гариза (почта адресын яисә дәүләт хезмәте алучы тарафыннан кредит оешмасында ачылган счет реквизитларын, компенсация алучының яшәгән урыны буенча теркәлгән гражданнар турында белешмәләрне күрсәтеп) (әлеге Регламентка 1 нче кушымта). Опекун (попечитель) дәүләт хезмәте алучыга акча күчерү өчен югарыда күрсәтелгән кредит оешмасында опекун (попечитель) тарафыннан ачтырылган номинал счет реквизитларын күрсәтә.<br>2. Социаль ярдәм чараларына хокук бирә торган таныклык күчермәсе.<br>Әлеге Регламентның 1.2 пунктының 5 пунктчасында күрсәтелгән гражданнар тарафыннан өстәмә рәвештә зарарланган зонадан чыгып китү фактын раслаучы белешмә тапшырыла.<br>Әлеге Регламентның 1.2 пунктының 14, 15, 16 пунктчаларында күрсәтелгән гражданнар тарафыннан өстәмә рәвештә тукландыручының үлеменә китергән авыруның радиация факторларына бәйләнешен билгеләү турында ведомствоара экспертлар советыннан (хәрби-табиблык комиссиясеннән) бәяләмәнең таныкланган күчермәсе тапшырыла. |

| | |
|---|---|
| | Опекун (попечитель) саналган документларга өстәмә рәвештә җирле үзидарә органыннан балага опека (попечительлек) билгеләү турында карарны тапшыра.<br>Дәүләт хезмәте алучы Россия Федерациясе гражданины паспортын күрсәтә.<br>Дәүләт хезмәте алучыларның законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә дәүләт хезмәте алучылар тарафыннан вәкаләт алган затлар өстәмә рәвештә дәүләт хезмәте алучының мәнфәгатьләрен кайгыртуга үзләренең вәкаләтле булуын дәлилләүче документларның күчермәләрен тапшыра.<br>Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.<br>Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан таныклана.<br>Дәүләт хезмәте алу буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша |

| | |
|---|---|
| | шул исәптән «Интернет» челтәре аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче аларны үзе тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе, шул исәптән электрон рәвештә; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша түбәндәге белешмәләрне раслаучы документлар алына:<br>балалар тууны дәүләт теркәвенә алу турында (гражданлык хәле актларын теркәү органнарында);<br>гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында (гражданлык хәле актларын теркәү органнары органнарында);<br>туклandыручының вафат булуы турында (гражданлык хәле актларын теркәү органнарында);<br>Россия Федерациясе Пенсия фонды территориаль органыннан пенсия алу факты турында (Россия Федерациясе Пенсия фонды территориаль органында);<br>компенсация алучының яшәгән урыны буенча теркәлгән граждannар турында (Россия Федерациясе эчке эшләр органнарында).<br>Мөрәҗәгать итүче шушы пункттагы белешмәләрдән торучы документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә, тапшырырга хокуклы.<br>Югарыда күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Мөрәҗәгать итүчедән югарыда санап үтелгән, дәүләт |

| | |
|---|---|
| | хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагында булган документларны тапшыруын таләп итү рөхсәт ителми |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча, норматив хокукый актларда каралган очракларда, алар белән килештерү таләп ителә торган һәм бу гамәл дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | Килештерү таләп ителми |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Шушы Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.<br>2. Үзәк бүлегенә 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законнар таләпләренә туры китереп, электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә гариза һәм документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру. |

| | |
|---|---|
| | 3. Документларда бетерелгән, өстәп язылган урыннарның, сызылган сүзләрнең һәм төзәтмәләрнең билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булуы.<br>4. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте алучының яшәү урынына карамаган Үзәк бүлегенә мөрәҗәгать итүе.<br>5. Әлеге Регламентның 1.3 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Ялган (төгәл булмаган) белешмәләрдән торучы документларны тапшыру дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми |

| | |
|---|---|
| кертеп | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте алучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән. |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәсен, шул исәптән электрон рәвештә, теркәүгә алу чоры | Гариза һәм документлар килгән көнне. Гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Үзәк бүлегенең ял көненнән яисә эшләми торган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урыннарына карата, шул исәптән аталган объектларның инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә инвалидлар өчен файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү турында | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгына каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга киртәләрсез үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла |

| | |
|---|---|
| визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматлар урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең үтемле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең читтән торып эшләү урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Үзәк бүлекләре бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, чорлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында тулы мәгълүматлар булуы;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>инвалидларга инвалидлар өчен бинаның үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачау итүкән бүтән каршылыкларны үтүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану; |

| | |
|---|---|
| мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып | белгечләрнең Регламентны бозуына карата прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булмау;<br>мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлеге белгечләре белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар почта аша җибәрелгәндә, – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлеге белгече белән бер мәртәбә эш итүенең дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан http://mtsz.tatarstan.ru/ сайтыннан, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан алынырга мөмкин |
| 2.16. Электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) Үзәк бүлегенә 63-ФЗ номерлы һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законнар таләпләренә туры китереп, электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм чорлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама

3.1.1. Компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) компенсация билгеләү буенча документлар җыелмасын кушып, гаризаны кабул итү һәм теркәү, яисә документларны кабул итүдән баш тарту;

3) мәгълүматлар алу, ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар әзерләү һәм кабул итү;

5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

6) техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге турында блок-схема шушы Регламентның 2 нче кушымтасында күрсәтелде.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә

Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон аша, почта, электрон почта ярдәмендә, шул исәптән, техник мөмкинлек булганда, Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, һәм (яисә) хат белән Үзәк бүлегенә дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итә.

Үзәк бүлеге белгече шәхсән телефон аша, почта, электрон почта ярдәмендә һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать ысулына карап, мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча, гариза бланкысын бирә һәм, зарурлык булганда, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: консультацияләү, тапшырылган документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча кисәтүләр, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны рәсмиләштерү өлешендә.

3.3. Компенсация билгеләү буенча документлар җыелмасын кушып, гаризаны кабул итү һәм теркәү, яисә документларны кабул итүдән баш тарту.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче компенсация билгеләү турында гаризаны Үзәк

бүлегенә, әлеге Регламентның 2.5 пунктына туры китереп, документлар күчермәләрен кушып тапшыра.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән тыш) почта аша заказ белән җибәрелергә мөмкин.

63-ФЗ номерлы һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законнар таләпләренә туры китереп имзаланган (таныкланган) гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) электрон документ рәвешендә җибәрелә ала.

Почта аша яисә электрон документ рәвешендә тапшырылган гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) әлеге Регламентның 3.3 пунктында каралган тәртиптә карала.

3.3.2. Үзәк бүлеге белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

дәүләт хезмәте алучының законлы вәкиле яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат сыйфатында гариза тапшыручының вәкаләтләрен тикшерә;

кирәкле барлык документларның булу-булмавын һәм аларның билгеләнгән таләпләргә (документларны тиешенчә рәсмиләштерү, документларда чистартылган, өстәп язылган, сүзләре сызылган урыннар һәм алдан сөйләшенмәгән башка төзәтү урыннары булу-булмавын) туры килү-килмәвен тикшерә.

Әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Идарә (бүлек) белгече аңа, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны кайтара.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Үзәк бүлеге белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм мөрәҗәгатьләрне теркәү журналында (3 нче кушымта) терки;

мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә – документларны кабул итү датасы, беркетелгән керү номеры турында тамгалап, мөрәҗәгать итүчегә язу тапшыра, гариза почта аша, шул исәптән электрон почта аша, җибәрелгәндә – документларны почта аша, шул исәптән электрон почта аша, кабул итү датасы турында хәбәрләмә җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар килгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гаризаларны теркәү журналында теркәү язуы, документларны кабул итүдән баш тарту турында язу яисә мөрәҗәгать итүчегә язмача хәбәр итү һәм мөрәҗәгать итүчегә кайтарылган документлар.

3.4. Мәгълүматлар алу, ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү

3.4.1. Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә түбәндәге белешмәләрне ала:

дәүләт хезмәте алучының Россия Федерациясе Пенсия фонды территориаль органыннан пенсия алуы факты турында Россия Федерациясе Пенсия фонды территориаль органыннан;

балалар тууны дәүләт теркәвенә алу турында гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан;

гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан;

тукландыручының вафат булуы турында гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан;

компенсация алучының яшәгән урыны буенча теркәлгән гражданнар турында Россия Федерациясе эчке эшләр органнарыннан.

3.4.2. Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында гарызнамәләр җибәрә:

Россия Федерациясе Пенсия фонды территориаль органына дәүләт хезмәтен алучыга пенсия билгеләү турында;

балалар тууны дәүләт теркәвенә алу турында гражданлык хәле актларын теркәү органнарына;

гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында гражданлык хәле актларын теркәү органнарына;

тукландыручының вафат булуы турында гражданлык хәле актларын теркәү органнарына;

компенсация алучының яшәгән урыны буенча теркәлгән гражданнар турында Россия Федерациясе эчке эшләр органнарына.

Әлеге пунктның 3.4.1 һәм 3.4.2 пунктчаларында билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар килгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон рәвештә алынган белешмәләр, мәгълүматлар бирү турында гарызнамәләр.

3.5. Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар әзерләү һәм кабул итү

3.5.1. Үзәк бүлеге белгече әлеге Регламентның 3.4.1 һәм 3.4.2 пунктчаларында күрсәтелгән белешмәләр һәм мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентның 4 нче кушымтасына туры китерелгән рәвештә билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар проекты рәсмиләштерә;

карар проектын имза салу өчен Үзәк бүлеге җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. Документларны ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша сорату зарурлыгы булганда, – гарызнамәләргә җавап килгән вакыттан башлап ике эш көне эчендә, ләкин гаризаны теркәгән көннән соң җиңе эш көненнән соңга калмыйча.

Процедураларның нәтиҗәсе: компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар.

3.5.2. Үзәк бүлеге җитәкчесе документларны караганнан соң компенсация

билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар проектына имза сала һәм Үзәк бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура документларны компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар проектын имза салу өчен җибәргән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Үзәк бүлеге җитәкчесе имзалаган билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

Үзәк бүлеге белгече:

компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) кабул ителгән карар хакында дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризада күрсәтелгән ысул белән (хат белән, телефон аша, смс-хәбәр, электрон почта ярдәмендә) мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә;

билгеләү турында карар кабул ителгән очракта, мөрәҗәгать итүченең шәхси эшен рәсмиләштерә (барлык документларны аерым папкага туплый).

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) кабул ителгән карар хакында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү, мөрәҗәгать итүченең рәсмиләштерелгән шәхси эше (уңай карар кабул ителү очрагында).

3.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү күпфункцияле үзәктә һәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.

3.8. Техник хаталарны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү

Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карарны үзгәртеп рәсмиләштерү компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карарда җибәрелгән техник хаталарны (язу, басма хаталарын, грамматик яисә арифметик хаталарны) юкка чыгаруга бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла.

Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карарны үзгәртеп рәсмиләштерү техник хатасы булган, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак тапшырылган документ (мондый документ бирелү очрагында) белән теркәлгән гариза (гаризаның киңәш ителә торган рәвеше шушы Регламентка 5 нче кушымтада китерелә) нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.8.1. Үзәк бүлеге белгече:

техник хата төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 3 нче кушымтасы);

компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар проектын үзгәртеп рәсмиләштерә;

компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар проектын имза салу өчен Үзәк бүлеге җитәкчесенә юллый.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан

башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хата төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, Үзәк бүлеге җитәкчесенә имза салу өчен юлланган компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар проекты.

3.8.2. Бүлеге җитәкчесе компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарга кул куя һәм аны Үзәк бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура карар проекты имза салу өчен җибәрелгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән, имзаланган карар.

3.8.3. Үзәк бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгәны ысул белән компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында хәбәр итә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Үзәк бүлекләрендәге белгечләрнең административ регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актларны саклавын һәм үтәвен көндәлек тикшереп тору Үзәк бүлеге җитәкчесе тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләрен саклауга һәм үтәүгә карата тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Үзәк бүлеге җитәкчесе тарафыннан карарлар кабул ителүне көндәлек тикшереп торуны оештыру тәртибе һәм рәвешләре Үзәк директоры тарафыннан билгеләнә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору Министрлык аппараты бүлегенең һәм Министрлыкның Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Социаль яклау идарәсенең (бүлегенең) (алга таба – Идарә (бүлек)) әлеге тикшереп торуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла, аларның вәкаләтләре Министрлыкның структур бүлекчәсе турында нигезләмәдә һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи регламентларында билгеләнә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору тикшерүләр уздыруны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрдән торучы мөрәҗәгатьләрне карауны, алар буенча карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләр уздыру ешлыгы планлы характерда (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерда (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) була.

4.2. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.3. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Үзәк бүлеге эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу мөмкинлеге һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карау юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның (хезмәткәрнең) яисә дәүләт граждан хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар судка кадәр тәртиптә Үзәк бүлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Үзәк бүлеге җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Үзәк җитәкчесе кабул иткән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Үзәк яисә Идарә (бүлек) җитәкчесенә тапшырыла.

Үзәк яисә Идарә (бүлек) җитәкчесе тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата шикаятьләр Министрлыкка министрның тикшереп торучы урынбасары яисә министр исеменә тапшырыла.

Министр урынбасары (министр) кабул иткән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына дәгъва белдерелергә мөмкин.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәсен теркәүгә алу чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив

хокукый актларында каралган гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган (учреждение), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат (учреждение хезмәткәре) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән чоры бозылганда.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Дәүләт хезмәте алучылар тарафыннан шикаять почтадан, күпфункцияле үзәктән, «Интернет» челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http//mtsz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталынан (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән чоры бозылганда, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) яисә граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) яшәгән урыны турында белешмәләр яисә аталышы, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта ) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре

(гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.6. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документларның исемлеге китерелә.

5.7. Шикаять аны тапшырган гариза бирүче тарафыннан имзалана.

5.8. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәте күрсәтүче орган (учреждение) түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган (учреждение) тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү, алынуы Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләүләрне мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук бүтән рәвешләрдә, канәгатьләндерә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Шушы пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яки, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

Техноген һәлакәтләр аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше
Үзәк бүлеге № ________
___________________________
муниципаль районында (шәһәрендә)

ГАРИЗА

№______ 20___ елның ____________________.

Мин,____________________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең тулысынча фамилиясе, исеме, атасының исеме)

түбәндәге адрес буенча яшим:_________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексы, телефоны, электрон почта адресы)

| Мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ аталышы | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

Түбәндәгегә нигезләнеп гамәл кылучы ___________________________________________________
_________________________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен алучы мәнфәгатьләрендә эшләү вәкаләтен раслаучы документ реквизитлары)

1. Түбәндәгеләргә нигезләнеп, азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләүне сорыйм:

«Чернобыль АЭСында һәлакәт аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законы;

«1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар элгү аркасында радиация тәэсиренә дучар булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында» 1998 елның 26 ноябрендәге 175-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Семипалат полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга социаль гарантияләр турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 2-ФЗ номерлы Федераль закон;

Россия Федерациясе Югары Советының «Чернобыль АЭСында һәлакәт аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» РСФСР Законы гамәленең аеруча куркыныч бүлекчәләрдәге гражданнарга кагылуы турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2123-1 номерлы карары (кирәклесе астына сызарга);

_________________________________________________________________________________
(дәүләт хезмәте алучының Ф.И.А.)

2. Билгеләнгән түләүне түбәндәгечә күчерүне сорыйм:

счет реквизитлары_________________________________________________________________
(дәүләт хезмәте алучы яисә аның законлы вәкиле тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә ачтырылган счет реквизитлары күрсәтелә)

почтадан җибәрү реквизитлары_______________________________________________________
(дәүләт хезмәтен алучының яисә аның законлы вәкиленең почтадан җибәрү реквизитлары күрсәтелә)

Гаризага түбәндәге документларны (күчермәләрне) һәм белешмәләрне терким:

| №<br>п/п | Документларның аталышы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |

3. Тапшырылган белешмәләрнең төгәллеге, шулай ук теркәлгән документларның хак булуы өчен җаваплы булам. Түләүләрне туктатуга (үзгәртүгә) китереп чыгаручы хәлләр барлыкка килүе турында вакытында хәбәр итү бурычы турында нигезләмә белән таныштым.

4. «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә әлеге Гаризада күрсәтелгән персональ мәгълүматларымны җыюга, эшкәртүгә (шул исәптән персональ мәгълүматларны автоматлаштырып эшкәртүгә), саклауга һәм персональ мәгълүматлар белән мәгълүмати алмашу системасында өченче затларга тапшыруга ризалыгымны бирәм.

______________________________________________________________________________,
(дәүләт хезмәте алучының Ф.И.А. күрсәтелә, шулай ук гариза дәүләт хезмәте алучының мәнфәгатьләрендә эш йөртүче зат тарафыннан тапшырылганда, – мөрәҗәгать итүченең)

______________________________________________________________________________.
(гариза бирүченең имзасы)

Мөрәҗәгать итүче:

_________________________________________________ __________ «__» ________ 20__ ел.
(Дәүләт хезмәте алучының, мөрәҗәгать итүченең яисә билгеләнгән тәртиптә танылканган ышанычнамә нигезендә дәүләт хезмәте алучының мәнфәгатьләрендә эш итүче затның Ф.И.А.) (имза)

5. Мәгълүматлар алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында), риза ___________________________________________________
(язмача, телефон аша, смс-хәбәр белән, электрон почта аша)

«__»________ 20__ ел. Имза _______________

Гариза һәм документлар кабул ителде _____ 20__ ел. __________ ___________________________
(белгеч имзасы, тулы имзасы)

___________________________________ _____________________________________________
*Өзү линиясе*


Язу-белдерүнамә

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү №____

Документлар саны _____ данә, __ биттә

Документларны кабул итте ________ __________ ________________ ________20____ел.
(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)

Техноген һәлакәтләр аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта



Техноген һәлакәтләр аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү
ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Гариза датасы | Гариза номеры | Гражданинның ФИА | Адресы | Мөрәҗәгать итү сәбәпләре | Мөрәҗәгать нәтиҗәләре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

Техноген һәлакәтләр аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Үзәк бүлеге № _________

____________________________
муниципаль районында (шәһәрендә)

«____»_________________ел. № ___________

Техноген һәлакәтләр аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында

КАРАР

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме:____________________________________
2. Туу елы_____________________________________________________
3. Яшәү урыны буенча адресы_________________________________________
4. Алучының категориясе
5. Түбәндәгеләргә нигезләнеп, компенсация билгеләргә:

«Чернобыль АЭСында һәлакәт аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законы

_________сум_____тиен күләмендә, ______ алып ______ кадәрге чор өчен;

«1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар элгү аркасында радиация тәэсиренә дучар булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында» 1998 елның 26 ноябрендәге 175-ФЗ номерлы Федераль закон

_________сум_____тиен күләмендә, ______ алып ______ кадәрге чор өчен;

«Семипалат полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга социаль гарантияләр турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 2-ФЗ номерлы Федераль закон

_________сум_____тиен күләмендә, ______ алып ______ кадәрге чор өчен;

Россия Федерациясе Югары Советының «Чернобыль АЭСында һәлакәт аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» РСФСР Законы гамәленең аеруча куркыныч бүлекчәләрдәге гражданнарга кагылуы турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2123-1 номерлы карары

_________сум_____тиен күләмендә, ______ алып ______ кадәрге чор өчен;

6. Яңадан башкарылган исәпләмә:_________________________________________
7. Компенсация артыннан мөрәҗәгать итү датасы___________________________
7. Компенсация билгеләүдән баш тартырга_________________________________
________________________________________________________________

Үзәк бүлеге җитәкчесе___________________________________
(имза) (тулы имза)

Белгеч____________________________________________________
(имза) (тулы имза)

Техноген һәлакәтләр аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

Үзәк бүлеге № _________

___________________________
муниципаль районында (шәһәрендә)

Техник хата төзәтү турында гариза

*Мин,* ___________________________________________________________________________
*(фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)*
түбәндәге адрес буенча яшим________________________________________________________
_________________________________________________________________________________
*(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)*
_________________________________________________________________________________
*(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ аталышы, аның сериясе, номеры, бирелү датасы,*
_________________________________________________________________________________
*документны биргән орган аталышы)*

шушы техник хатаны төзәтүне сорыйм_____________________________________, ул социаль ярдәм чараларын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында әлеге карарда җибәрелгән:
______________ № ____________________________
*карар датасы* *карар номеры*

Техник хатаны төзәтү турында мәгълүмат алуга риза
_________________________________________________________________________________
(язмача, телефон аша, смс-хәбәр белән, электрон почта аша)

«__»________ 20__ ел. Имза ______________

«___» ______________ 20___ ел. ____________________ _______________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имзасы)

Техноген һәлакәтләр аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмә)

**Техноген һәлакәтләр аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр**

1. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Директоры | 523-90-40 | koord.rcmp@tatar.ru |

2. Республика матди ярдәм үзәге бүлекләре

| Булекнең аталышы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| Республика матди ярдәм үзәгенең "Чаллы" шәһәр округындагы № 1 бүлеге | (8552) 47-46-53 47-46-54 | 423823, Татарстан Республикасы, Чаллы ш., Кояшлы бульвар, 6 й., №1 подъезд; 423823, Татарстан Республикасы, Чаллы ш., Кояшлы бульвар, 6 й., №2 подъезд; chl.1@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең "Чаллы" шәһәр округындагы № 2 бүлеге | (8552) 71-47-02, 71-49-39, 71-80-35 | 423850, Татарстан Республикасы, Чаллы ш., Гидротөзүчеләр ур., 14 chl.2@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Әгерҗе муниципаль районындагы № 2 бүлеге | (85551) 2-42-33 2-28-32 | 422230, Татарстан Республикасы, Әгерҗе ш., Карл Маркс ур., 11А й. agr.2@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Азнакай муниципаль районындагы № 3 бүлеге | (85592) 7-25-93, 7-13-99 | 423330, Татарстан Республикасы, Азнакай ш., Болгар ур., 9/2 й. azn.3@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Аксубай муниципаль районындагы № 4 бүлеге | (84344) 2-92-76 2-92-75 | 423060, Татарстан Республикасы, Аксубай ш.т.п., Мазилин ур., 2 й. aks.4@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Республика матди ярдәм үзәгенең Актаныш муниципаль районындагы № 5 бүлеге | (85552)<br>3-22-97<br>3-22-96 | 423740, Татарстан Республикасы, Актаныш ав., Юбилей ур., 45 й.<br>akt.5@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Алексеевск муниципаль районындагы № 6 бүлеге | (84341)<br>2-37-73,<br>2-53-01,<br>2-32-75 | 422900, Татарстан Республикасы, Алексеевск ш.т.п., Казаков ур., 8<br>ale.6@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Әлки муниципаль районындагы № 7 бүлеге | (84346)<br>2-08-94 | 422870, Татарстан Республикасы, Базарлы Матак ав., Ленин ур., 9<br>alk.7@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Әлмәт муниципаль районындагы № 8 бүлеге | (8553)<br>43-81-96<br>32-45-48<br>32 45 47 | 423452, Татарстан Республикасы, Әлмәт ш., Клара Цеткин ур., 54а й<br>alm.8@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Апас муниципаль районындагы № 9 бүлеге | (84376)<br>2-10-98 | 422350, Татарстан Республикасы, Апас ш.т.п., Шоссе ур., 5 й.<br>apa.9@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Арча муниципаль районындагы № 10 бүлеге | (84366)<br>3-13-30<br>3-13-34 | 422000, Татарстан Республикасы, Арча ш., Банк ур. 6в й.<br>ars.10@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Әтнә муниципаль районындагы № 11 бүлеге | (84369)<br>2-16-55<br>2-16-53 | 422750, Татарстан Республикасы, Олы Әтнә ав., Октябрь ур., 9 й.<br>atn.11@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Баулы муниципаль районындагы № 12 бүлеге | (85569)<br>5-67-22<br>5-64-42 | 423930, Татарстан Республикасы, Баулы ш., Җиңү м., 4 й.<br>bav.12@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Балтач муниципаль районындагы № 13 бүлеге | (84368)<br>2-57-94<br>2-64-32<br>2-41-37 | 422250, Татарстан Республикасы, Балтач ш.т.п., Һади Такташ ур., 3а<br>bal.13@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Бөгелмә муниципаль районындагы № 14 бүлеге | (85594)<br>5-00 56<br>5-02-77<br>5-02-50 | 423239, Татарстан Республикасы, Бөгелмә ш., Стрелочная ур., 1 й.<br>bug.14@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Буа муниципаль районындагы № 15 бүлеге | (84374)<br>3-17-03<br>3-41-80 | 422430, Татарстан Республикасы, Буа ш., Ленин ур., 52 й.<br>bui.15@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Югары Ослан муниципаль районындагы № 16 бүлеге | (84379)<br>2-13-01 | 422570, Татарстан Республикасы, Югары Ослан ав., Медгородок ур., 21а й.<br>usl.16@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Биектау муниципаль районындагы № 17 бүлеге | (84365)<br>2-32-53<br>2-40-09 | 422700, Татарстан Республикасы, Биектау ст., Профсоюз ур., 1а й.<br>gor.17@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Республика матди ярдәм үзәгенең Чүпрәле муниципаль районындагы № 18 бүлеге | (84375)<br>2-25-80<br>2-23-24 | 422470, Татарстан Республикасы, Иске Чүпрәле ав., Үзәк ур., 15 й.<br>dro.18@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Алабуга муниципаль районындагы № 19 бүлеге:<br><br>Республика матди ярдәм үзәгенең Алабуга муниципаль районындагы № 19 бүлегенең өстәмә пункты | (85557)<br>7-54-53<br>7-87-82 | 423600, Татарстан Республикасы, Алабуга ш., Спас ур., 3 й.<br><br>423600, Татарстан Республикасы, Алабуга ш., Нефтьчеләр ур., 12 й.<br>ela.19@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Зәй муниципаль районындагы № 20 бүлеге | (85558)<br>7-10-46<br>7-02-64 | 423520, Татарстан Республикасы, Зәй ш., Рафиков ур., 10 й.<br>zai.20@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Яшел Үзән муниципаль районындагы № 21 бүлеге | (84371)<br>5-80-01<br>5-79-90 | 420542, Татарстан Республикасы, Яшел Үзән ш.,Карл Маркс ур.,57вй.<br>zel.21@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Кайбыч муниципаль районындагы № 22 бүлеге | (84370)<br>2-11-13<br>2-14-07 | 422330, Татарстан Республикасы, Зур Кайбыч ав.,<br>Кояшлы бульвар ур., 7 й.<br>kai.22@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Кама Тамагы муниципаль районындагы № 23 бүлеге | (84377)<br>2-16-84 | 422820, Татарстан Республикасы, Кама Тамагы ш.т.п.,<br>Карл Маркс ур., 2 й.<br>kam.23@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Кукмара муниципаль районындагы № 24 бүлеге | (84364)<br>2-61-09<br>2-83-94 | 422110, Татарстан Республикасы, Кукмара ш.,Ворошилов ур.,44 й.<br>kuk.24@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Лаеш муниципаль районындагы № 25 бүлеге | (84378)<br>2-55-82<br>2-44-73 | 422610, Татарстан Республикасы, Лаеш ш., Первомайская ур., 35 й.<br>lai.25@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Лениногорск муниципаль районындагы № 26 бүлеге | (85595)<br>5-05-40<br>5-08-05<br>5-55-71<br>6-10-45 | 423258, Татарстан Республикасы, Лениногорск ш., Гагарин ур., 51 й.<br>len.26@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Мамадыш муниципаль районындагы № 27 бүлеге | (85563)<br>3-29-82<br>3-22-83 | 422190, Татарстан Республикасы, Мамадыш ш., Совет ур., 10 й.<br>mam.27@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Менделеевск муниципаль районындагы № 28 бүлеге | (85549)<br>2-19-72<br>2-02-27 | 423650, Татарстан Республикасы, Менделеевск ш.,<br>Бурмистров ур., 7а й.<br>mnd.28@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Республика матди ярдәм үзәгенең Минзәлә муниципаль районындагы № 29 бүлеге | (85555)<br>3-18-22<br>3-10-50<br>3-33-28 | 423700, Татарстан Республикасы, Минзәлә ш., Ленин ур., 80 й.<br>mnz.29@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Мөслим муниципаль районындагы № 30 бүлеге | (85556)<br>2-38-34<br>2-47-50 | 423970, Татарстан Республикасы, Мөслим ав., Пушкин ур., 47 й.<br>mus.30@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Түбән Кама муниципаль районындагы № 31 бүлеге<br><br>Республика матди ярдәм үзәгенең Түбән Кама муниципаль районындагы<br>№ 31 бүлегенең өстәмә пункты | (8555)<br>45-44-92 | 423570, Татарстан Республикасы, Түбән Кама ш., Тынычлык пр., 60<br><br>423570, Татарстан Республикасы, Түбән Кама муниципаль районы, Кама Аланы ш.т.п.,<br>Ильич ур., 2/01 й.<br>niz.31@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Яңа Чишмә муниципаль районындагы № 32 бүлеге | (84348)<br>2-22-98<br>2-20-30 | 423190, Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә ав., Совет ур., 80 й.<br>nov.32@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Нурлат муниципаль районындагы № 33 бүлеге | (84345)<br>2-06-86<br>2-06-65 | 423040, Татарстан Республикасы, Нурлат ш., Пушкин ур., 46 й.<br>nur.33@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Питрәч муниципаль районындагы № 34 бүлеге | (84367)<br>3-00-15<br>3-02-90 | 422770, Татарстан Республикасы, Питрәч ав., Совет ур., 20 й.<br>pes.34@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Балык Бистәсе муниципаль районындагы № 35 бүлеге | (84361)<br>2-20-98 | 442650, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе ш.т.п.,Завод ур.,6а й.<br>ryb.35@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Саба муниципаль районындагы № 36 бүлеге | (84362)<br>2-28-17<br>2-28-19 | 422060, Татарстан Республикасы, Байлар Сабасы ш.т.п.,<br>Закир Йосыпов ур., 7 й.<br>sab.36@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Сарман муниципаль районындагы № 37 бүлеге<br><br>Республика матди ярдәм үзәгенең Сарман муниципаль районындагы № 37 бүлегенең өстәмә пункты | (85559)<br>2-57-32<br>2-44-05 | 423350, Татарстан Республикасы, Сарман ав., Куйбышев ур., 36 й.<br><br>423368, Татарстан Республикасы, Сарман районы, Җәлил ш.т.п., Җиңүгә 30 ел ур., 13 й.<br>sar.37@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Спас муниципаль районындагы № 38 бүлеге | (84347)<br>3-97-43<br>3-93-27 | 422840, Татарстан Республикасы, Болгар ш., Пионер ур., 21 й.<br>spa.38@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Республика матди ярдәм үзәгенең Тәтеш муниципаль районындагы № 39 бүлеге | (84373)<br>2-62-33,<br>2-62-39 | 422370, Татарстан Республикасы, Тәтеш ш., Ленин ур., 114 й.<br>tet.39@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Тукай муниципаль районындагы № 40 бүлеге | (8552)<br>71-32-00 | 423802, Татарстан Республикасы, Чаллы ш., Есенин пр., 1 й.<br>tuk.40@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Теләче муниципаль районындагы № 41 бүлеге | (84360)<br>2-17-39 | 422080, Татарстан Республикасы, Теләче ав., Зур Тау ур., 5 й.<br>tul.41@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Чирмешән муниципаль районындагы № 42 бүлеге | (84396)<br>2-26-34 | 423100, Татарстан Республикасы, Чирмешән ав., Титов ур., 26 й.<br>chr.42@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Чистай муниципаль районындагы № 43 бүлеге | (84342)<br>5-33-98<br>5-21-60 | 422980, Татарстан Республикасы, Чистай ш., Урицкий ур., 45 й.<br>chs.43@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Ютазы муниципаль районындагы № 44 бүлеге | (85593)<br>2-79-26 | 423950, Татарстан Республикасы, Урыссу ш.т.п., Пушкин ур., 105/1<br>uta.44@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Авиатөзелеш районындагы бүлеге | (8843)<br>571-63-71<br>570-06-41 | 420036, Татарстан Республикасы, Казан ш., Тимирязев ур., 8 й.<br>avi.k@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Вахитов районындагы бүлеге | (8843)<br>238-10-54<br>238-10-55 | 420197, Татарстан Республикасы, Казан ш., Вишневский ур., 10 й.<br>vah.k@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Киров районындагы бүлеге<br><br>Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Киров районындагы бүлегенең өстәмә пункты | (8843)<br>554-64-69<br>555-51-80<br><br>294-37-42 | 420102, Татарстан Республикасы, Казан ш., Галимҗан Баруди ур., 5<br><br>420078, Татарстан Республикасы, Казан ш., Ильич ур., 21/8 й.<br>kir.k@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Мәскәү районындагы бүлеге | (8843)<br>554-00-65<br>554-03-45 | 420102, Татарстан Республикасы, Казан ш., Галимҗан Баруди ур., 5<br>mos.k@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Яңа Савин районындагы бүлеге | (8843)<br>523-56-08 | 420124, Татарстан Республикасы, Казан ш., Хөсәен Ямашев пр., 37 й<br>sav.k@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Идел буе районындагы бүлеге | (8843)<br>224-32-05<br>224-30-61<br>224-19-09<br>224-04-20 | 420110, Татарстан Республикасы, Казан ш., Рихард Зорге ур., 39 й. |

| | | |
|---|---|---|
| Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Идел буе районындагы бүлегенең өстәмә пункты | 224-32-17<br><br>598-06-23 | 420054, Татарстан Республикасы, Казан ш., Авангард ур, 74 й.<br>pri.k@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Совет районындагы бүлеге<br><br>Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Совет районындагы бүлегенең өстәмә пунктлары | (8843)<br>272-51-79<br>272-16-72<br><br>239-63-83<br><br>262 90 60<br><br>262 93 66 | 420073, Татарстан Республикасы, Казан ш., Гадел Кутуй ур., 33 й.<br><br>420075, Татарстан Республикасы, Казан ш., Совет ур., 23 й.<br><br>420100, Татарстан Республикасы, Казан ш., Галия Кайбицкая ур., 3<br><br>420140, Татарстан Республикасы, Казан ш.,<br>Җиңү Проспекты ур., 100 й.<br>sov.k@tatar.ru |

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-08 | Natalya.Bytaeva@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының методология бүлеге башлыгы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының аудит бүлеге башлыгы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru |

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы | 264-77-29 | pisma@tatar.ru |